Республика Татарстан Камско- Устьинский муниципальный район
МБОУ « Старо- Казеевская СОШ »

# Конкурс цифровых образовательных ресурсов

## Номинация : предметы начальной школы

Автор работы: Сафина Мадина Салиховна
учительница начальных классов
МБОУ « Старо-Казеевская СОШ»
Камско – Устьинского муниципального
района РТ.

2011- 2012 учебный год.

# Башлангыч сыйныфта татар теленнән кагыйдәләр



# Татар теленең төп темалары

- Алфавит
- Авазлар һәм хәрефләр
- Сүз төзелеше
- Кушымчаларның төрләре
- Сүз ясалышы
- Сүз төркемнәре

- Бәйлек һәм бәйлек сүзләр
- Кисәкчә
- Сүз. Җөмлә
- Җөмлә төрләре
- Сүзтезмә
- Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре
- Текст

Аваз  һәм хәреф

Сузык авазлар
һәм  хәрефләр

О  хәрефе

Ө хәрефе

Э, е  хәрефләре

Тартык авазлар һәм
хәрефләр

В   хәрефе

К хәрефе

ГГ Г  хәрефе

Х, һ
хәрефләре

Й  хәрефе

Е  хәрефе

Я    хәрефе

Ю    хәрефе

Ь  Ь
хәрефе

Ъ  хЪ
хәрефе

Ижек.Сузләрне
юлдан –
юлга күчерү.

Сүзгә аваз – хәреф
анализы

# Сүз төркемнәре

Исем. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр

Исемнең берлек һәм күплек санда килүе

Татар телендә килешләр

ИсемнеИсемнең килеш белән төрләнеше ( берлек сан)

ИсемнеИсемнең килеш белән төрләнеше ( күплек сан)

ФигылФигыль

Боерык фигылБоерык фигыльнеБоерык фигыльнең зат-сан формалары

Хикәя фигылХикәя фигыльнеХикәя фигыльнең заман формалары

Хәзерге заман хикәя фигылХәзерге заман хикәя фигыльнеХәзерге заман хикәя фигыльнең зат – сан белән төрләнеше.

Үткән заман хикәя фигылҮткән заман хикәя фигыльнеҮткән заман хикәя фигыльнең зат – сан белән төрләнеше.

Киләчәк заман хикәя фигылКиләчәк заман хикәя фигыльнеКиләчәк заман хикәя фигыльнең зат – сан белән төрләнеше.

Сыйфат

Сыйфат дәрәҗәләре

Зат алмашлыклары

Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше



# Алфавит

**Алфавитта һәр хәрефнең билгеле урыны һәм исеме бар.**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Аа | а | Лл | эль | Хх | ха |
| Әә | ә | Мм | эм | Һһ | һэ |
| Б б | бэ | Нн | эн | Цц | цэ |
| Вв | вэ | ң | эң | Чч | чэ |
| Гг | гэ | Оо | о | Шш | ша |
| Дд | дэ | Өө | ө | Щщ | ща |
| Ее, Ёё | йы, йо | Пп | пэ | ъ | калынлык һәм |
| Жж | жэ | Рр | эр | | аеру билгесе |
| Җҗ | җэ | Сс | эс | Ыы | ы |
| Зз | зэ | Тт | тэ | ь | нечкәлек һәм |
| Ии | и | Уу | у | | аеру билгесе |
| Йй | кыска и | Үү | ү | Ээ | э |
| Кк | ка | Фф | эф | Юю | йу |
| | | | | Яя | йа |

# Аваз һәм хәреф

Сүзләр авазлардан төзелә

Авазларны әйтәбез һәм ишетәбез.

Язуда авазлар хәрефләр белән белдерелә.

Хәрефне язабыз һәм күрәбез.



[ алма]

алма



[кишэр]

кишер

# Сузык авазлар һәм хәрефләр

Татар телендә 12 сузык аваз бар.
Калын сузык авазлар : [а ] [о] [у] [ ы] [ы̄] [о̄]

Нечкә сузык авазлар : [ә ] [ө ] [ү] [э] [э̄] [и]

парлы парсыз

[ы̄], [э̄], [о̄] авазлары рус теленнән кергән сүзләрдә генә кулланыла

[посылка] [экран] [ кино]

Сузык авазлар тавыштан гына торалар.

А - а - а! У - у - у! Ы – ы –ы! О – о - о!
Ә - ә - ә! Ү ү - ү! Э - э – э ! Ө – ө – ө!

Сузык авазлар язуда а, ә, о, ө, у, ү, ы, э, и хәрефләре белән белдерелә

# О хәрефе

О хәрефе татар телендә сүзнең беренче иҗегендә генә языла:
ор – лык, йол – дыз, тор – мыш.

Рус сүзләрендә о хәрефе төрле иҗекләрдә языла:
ки – но, па – ро – воз, про – жек – тор.

Татар сүзләренең беренче иҗегендә [о] авазы булганда, икенче
иҗектәге [ы] авазы “о” лаштырып әйтелә:
языла – болын, әйтелә – [ болон].

Дөрес яз!

| | |
|---|---|
| болын | герой |
| болыт | метро |
| йолдыз | кино |
| йокы | пароход |
| орлык | эшелон |
| тормыш | мотор |



# Ө хәрефе

**Ө хәрефе сүзнең беренче иҗегендә генә язылa.**

**Сүзнең беренче иҗегендә [ө] авазы килгәндә, икенче иҗектәге [э] авазы “ ө” ләштереп әйтелә.**
**язылa – төрле, әйтелә – [ төрлө]**
**язылa – дөрес , әйтелә – [ дөрөс]**

**Дөрес яз!**



| | | |
|---|---|---|
| сөтле | төрле | бөртек |
| көндез | сөлге | төркем |
| көзге | йөзек | төлке |
| көлке | дөрес | төзек |
| көчле | төтен | төзелеш |

# Э,е хәрефләре

Язуда [э] авазын белдерү өчен, сүз башында – э хәрефе, башка урыннарда е хәрефе языла:

эзле, элекке, элемтәче

Э, е хәрефләре нечкә сузыкларны күрсәтә.

Татар теленең үз сүзләрендә э, е хәрефләре кыскарак әйтелә торган [э] авазын белдерәләр:

[эскэрт] , [эшчэ] , [кэшэ] .

Рус телендә ул сузыбрак әйтелә торган [э] авазын белдерә:

[этаж] , [эстафэта] , [элэктрон] .

**Истә калдыр!**

| сүз башында | сүз уртасында | сүз ахырында |
|---|---|---|
| эш | элгеч | эссе |
| эз | эремчек | энҗе |
| эл | эрелек | эре |
| эт | элемтә | элемтәче |
| эч | элек | кеше |

# Тартык авазлар һәм хәрефләр

Татар телендә 28 тартык аваз бар.

Яңгырау тартык авазлар: [б],[в], [г],[гъ],[д],[ж],[җ],[з] [л],[м],[н],[ң],[й],[р],[w]

Саңгырау тартык авазлар: [п],[ф],[к],[къ],[т],[ш],[ч],[с] [ц],[щ],[х],[һ],[’] (һәмзә)

парлы парсыз

**[ц],[щ] авазлары рус теленнән кергән сүзләрдә генә кулланыла**

**Тартык авазлар язуда**

**б, п, в, ф, г, к, д, т, ж, ш, җ, ч, з, с, л, м, н, ң, й, р, ц, щ, х, һ**

**хәрефләре белән белдерелә**

**[гъ],[къ],[w],[’] авазлары өчен махсус хәрефләр юк.**

**Гата – [гъата] кар – [къар] ватан – [wатан]**

**дәү – [дәw] мәсьәлә – [мәс’әлә]**

**Тартык авзлар тавыш һәм шаудан яки шаудан гына торалар**

# В хәрефе

В хәрефе татар телендә ике авазга билге булып йөри.
Татар һәм гарәп сүзләрендә в хәрефе [w] авазын белдерә.
Калын сүзләрдә [w] авазы [у] авазына якын әйтелә:
авыл [аwыл], ватан [wатан].
Нечкә сүзләрдә [w] авазы [ү] авазына якын әйтелә:
вәгъдә [wәгъдә], гөрләвек [гөрләwәк], Вәсимә [wәсимә]
Рус теленнән кергән сүзләрдә в хәрефе рус телендәгечә әйтелә:
за<u>в</u>од, <u>в</u>агон, <u>в</u>етеран

Сүзләрне дөрес әйтегез!



| | | | |
|---|---|---|---|
| авыл | [аwыл] | тавыш | [таwыш] |
| аваз | [аwаз] | җавап | [ җаwап] |
| авыр | [аwыр] | һава | [һаwа] |
| вакыт | [wакъыт] | ява | [йаwа] |
| ватан | [wатан] | ава | [аwа] |
| валчык | [wалчыкъ] | сава | [саwа] |
| давыл | [ даwыл] | хайван | [ хайwан] |
| савыт | [саwыт] | әвәләү | [ әwәләү] |
| тавык | [таwык] | Вәсилә | [ wәсилә] |
| кавын | [ каwын] | Вәсимә | [wәсимә] |

# К хәрефе

К хәрефе язуда ике авазга билге булып йөри.
Калын сүзләрдә ул каты укыла. Моны сүздәге сузык авазга карап беләбез.

колак- [о], [а] – калын сузыклар, шуңа күрә [ къолакъ] дип әйтелә.

Нечкә сүзләрдә к йомшак укыла:

[көз], [көрәк], [кәбэстә], [кирәк], [кэрпэ], [күмәч].

## Сүзләрне дөрес әйтегез!

| | | |
|---|---|---|
| калкулык | кәлтә | карта |
| кунак | күбәләк | куртка |
| коңгыз | көрәк | компьютер |
| кырмыска | керфек | кефир |



# Г хәрефе

**Татар телендә г хәрефе ике авазга билге булып йөри.**
**Калын сүзләрдә ул** **каты [гъ]** **авазын белдерә:**
**суган [сугъан] , колга [къолгъа].**
**Нечкә сүзләрдә г хәрефе** **йомшак [г]** **авазын белдерә:**
**[гөл], [тигэз].**

## Дөрес укы һәм дөрес яз!

| | | | |
|---|---|---|---|
| **гадәт** | **[ гъәдәт ]** | **газиз** | **[гъәзиз]** |
| **гайрәт** | **[гъәйрәт]** | **гаскәр** | **[гъәскәр]** |
| **гаҗәп** | **[ гъәҗәп ]** | **галәмәт** | **[гъәләмәт]** |
| **галәм** | **[гъәләм ]** | **гарәп** | **[гъәрәп]** |
| **гадел** | **[гъәдел ]** | **гаеп** | **[гъәйэп]** |

**Гарәп теленнән кергән сүзләрдәге а хәрефе г хәрефен [гъ] авазы итеп**
**укырга кирәклекне күрсәтә. Мондый сүзләрдә а хәрефе [ә] дип укыла.**

| Татар сүзләре | Гарәп теленнән кергән сүзләр | Рус сүзләре |
|---|---|---|
| агым | гадәт | газ |
| боргыч | газиз | гармун |
| гүзәл | вәгъдә | грамм |
| гөрләү | мәгъна | герб |

# X,h хәрефләре

**Сүзләрне дөрес укы һәм дөрес яз!**

| х | һ |
|---|---|
| хат | һава |
| хәл | һәйкәл |
| хушлашу | һөнәр |
| хөрмә | һәркем |
| халык | һаман |
| хәтер | һуш |
| хезмәт | һәммә |
| пөхтә | шәһәр |
| рөхсәт | зиһен |
| бәхет | җиһаз |
| Хәмит | һәҗәр |
| Хәдичә | Фәһимә |

# Й хәрефе

Й хәрефе сүзләрнең башында, уртасында һәм ахырында килә:
йомры, йөз, сөйләм, бабай.

Йо, йө сүз башында гына языла: йомран, йомгак, йомырка,
йөткерү, йөгереш,йөрү.

Йо – калын әйтелешле сүзләрдә, йө – нечкә әйтелешле сүзләрдә языла.

Дөрес яз!

| | | | |
|---|---|---|---|
| йолдыз | йөзек | бәйрәм | май |
| йомшак | йөзү | тыйнак | туй |
| йозак | йөрәк | койма | җәй |



# Е хәрефе

**Е хәрефе** сүз һәм иҗек башында [йы] [йэ] аваз кушылмаларын белдер

**Калын сүзләрдә** ул **[йы]** дип укыла: ел [ йыл], куе [ку-йы] .

**Нечкә сүзләрдә [йэ]** дип укыла: биек [би-йэк], егет [йэ-гэт]/

| Дөрес язызгыз һәм дөрес әйтегез! | | | |
|---|---|---|---|
| е [йы] | | е [йэ] | |
| **язылa** | **укыла** | **язылa** | **укыла** |
| ел | [ йыл] | ефәк | [йэфәк] |
| ерак | [йыракъ] | егет | [йэгэт] |
| елга | [йылгъа] | тиен | [тийэн] |
| елан | [ йылан] | кием | [кийэм] |
| быел | [быйыл] | биек | [бийэк] |
| каен | [ къайын] | төен | [төйөн] |
| ертык | [йыртыкъ] | егерме | [йэгэрмэ] |
| еш | [йыш] | бөер | [бөйөр] |
| каеш | [къайыш[ | төер | [төйөр] |

# Я хәрефе

Я хәрефе [йа], [йә] аваз кушылмаларына билге булып йөри.
Калын сүзләрдә я хәрефе [йа] дип укыла:
язу [йазу], якты [йакты].
Нечкә сүзләрдә я хәрефе [йә] дип укыла:
яшел [йәшел], ярдәм [йәрдәм].

| Дөрес языгыз һәм дөрес әйтегез! | | | |
|---|---|---|---|
| я [йа] | | [я йә] | |
| языла | укыла | языла | укыла |
| ябалак | [йабалакъ] | янәшә | [йәнәшә] |
| ягулык | [йагулыкъ] | яшел | [йәшэл] |
| язу | [йазу] | яшелчә | [йәшэлчә] |
| яка | [йакъа] | яшен | [йәшэн] |
| яңгыр | [йаңгъыр] | ярдәм | [йәрдәм] |

# Ю хәрефе

Ю хәрефе - йу йү аваз кушылмаларын белдерә.

Калын сүзләрдә ю хәрефе [йу] дип укыла:
юлдаш [йулдаш ], юан [йуан].

Нечкә сүзләрдә ю хәрефе [йү] дип укыла:
юкә [йүкә], юеш [ йүэш].

Дөрес әйтегез һәм дөрес языгыз!

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| юка | [йукъа] | юаш | [йуаш] | тою | [тойу] |
| юкә | [йүкә] | ютәл | [йүтәл ] | төю | [төйү] |



# ь хәрефе

Сүзләрнең нечкә әйтелешен белдерү өчен сүз ахырында ь хәрефе языла: ямь, яшь, япь, юнь һ.б.;

ь хәрефе иҗекләрнең нечкә укылышын да күрсәтә:

ятьмә, ямьле һ.б. ;

Гарәп теленнән кергән сүзләрдә ь билгесе иҗекнең нечкә
әйтелешен күрсәтү өчен языла:

сәгать, табигать, шагыйрь шигырь һ.б. ;

Нечкә иҗек ахырындагы ь хәрефе, я, ю, е хәрефләре алдыннан килгәндә, тартыкларны аерып укуны белдерә:
дөнья [дөнйа], көньяк [көнйакъ], берьюль
бишьеллык [бишйыллыкъ]



# ъ хәрефе

Нечкә иҗекләрдәге **к, г** хәрефләрен [къ], [гъ] дип уку өчен, язуда иҗек ахырында **ъ хәрефе** куела:

**мәгълүм, игълан, тәкъдим, икътисад һ.б.**

**ъ хәрефе,** калын иҗектән соң **я, ю, е** хәрефләре алдыннан килгәндә, тартыкларны аерып укырга кирәклекне күрсәтә:

**аръяк [арйакъ], кульяулык [къулйаулыкъ]**

**Исеңдә тот!**

| ъ калынлыкны белдерә | ъ аеруны белдерә |
|---|---|
| нәкъ<br>вәгъдә<br>мәгънә<br>мәгълүм<br>игътибар<br>тәкъдим | ашъяулык<br>кулъяулык<br>унъеллык<br>елъязма<br>аръяк<br>алъяпкыч |



# Иҗек.Сүзләрне юлдан – юлга күчерү.

Сүз иҗекләргә бүленә.
Сүздә ничә сузык аваз булса, шулкадәр иҗек була.



бү – рә - нә

Сүз юлдан – юлга иҗекләп күчерелә.
Бер генә хәрефне юл азагында калдырырга яки яңа юлга күчерергә ярамый.

кү – гәр – чен сан – ду – гач оя

Й, ъ, ь хәрефләре үзләреннән алда торган хәреф янында кала

көй – мә игъ –ти –бар мәсь - әлә

# Сүзгә аваз – хәреф анализы



1. Сүзне әйт: [ йылгъа]
2. Сүзне иҗекләргә бүл: ел – га.
3. Сүздә ничә хәреф, ничә аваз бар? 4 хәреф, 5 аваз
4. Хәрефләрне яз: е, л, г, а
5. Авазларны яз: [й], [ы], [л],[гъ],[а]
6. Сузык һәм тартык авазларны аерып яз: [ы], [а];[й],[л],[гъ]
7. Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аерып яз:
   [й], [л], [гъ] – яңгырау тартыклар,
   саңгырау тартыклар юк.
8. Хәреф саны белән аваз саны туры килми, чөнки е хәреф
   [й] һәм [ы] авазлары кушылмасын белдерә.
9. Сүзнең әйтелеше белән язылышы туры килү – килмәвен әйт:
   сүзнең әйтелеше белән язылышы туры килми, чөнки е хәрефе
   ике аваз кушымасын белдерә.

# Сүз төзелеше

**Сүз тамырдан яисә тамыр һәм кушымчалардан тора.**
**Тамыр һәм кушымча сүзнең мәгънәле кисәкләре дип йөртелә.**

**Тамыр сүзнең төп мәгънәсен белдерә, мәгънәле кисәкләргә таркалмый**

**авыл** - төп мәгънә

**Кушымча сүзнең мәгънәсен яки формасын үзгәртә, аерым кулланылмый.**

**авыл – даш** – сүзнең мәгънәсе үзгәргән

**авыл – га** – сүзнең формасы үзгәргән

**Бер тамырдан ясалган сүзләр тамырдаш сүзләр дип атала.**
**Тамырдаш сүзләр арасында мәгънә бәйләнеше була**





**җиләк**
**җиләк – ле**
**җиләк - лек**

тамырдаш сүзләр

**Тамырдаш сүзләрне охшаш яңгырашлы сүзләр белән бутама!**
**Мәсәлән : бала, балавыз сүзләре тамырдаш түгел.**

# Кушымчаларның төрләре

| Сүз ясагыч кушымча яңа сүз ясый | Сүз төрләндергеч кушымча сүзнең формасын үзгәртә. |
| --- | --- |
| -чы/-че; -лык/ -лек;<br>-даш/ -дәш, - таш/ - тәш;<br>-гыч/ - геч, -кыч/ - кеч;<br>-гы/ -ге, - кы/ - ке;<br>-сыз/ - сез; -лы/ - ле;<br>- ла/ - лә һ.б. | -лар/ - ләр, - нар/ - нәр;<br>-кай/ - кәй; - чык/- чек;<br>-сыл/ - сел; - рак/ - рәк;<br>-ынчы/ - енче;<br>-га/ - гә, - ка/ - кә;<br>-ар/ - әр һ.б. |
| авыл - **даш** | авыл - **лар** |

**Бер тамырга берьюлы берничә кушымча ялганырга мөмкин:**

авыл – **даш- лар –ым - ны**

# Сүз ясалышы.



гөмбә
тамыр сүз

гөмбәче
ясалма сүз



**Тамыр сүз – ясагыч кушымчасы булмаган сүз.**
**Тамырына ясагыч кушымча ялганган сүзләр: кушма, парлы, тезмә сүзләр – ясалма сүзләр.**

**Кушма сүз** ике сүз кушылып ясала, кушылып языла: **төньяк, аккош, алъяпкыч**

**Парлы сүз** ике сүз теркәлеп ясала, бер мәгънә белдерә, сызыкча аша языла: **әти – әни, уен – көлке, аклы - каралы**

**Тезмә сүз** ике яки берничә сүз тезелеп ясала, бер мәгънә белдерә аерым языла: **катылык билгесе, кура җиләге, үги ана яфрагы**

# Исем. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр.

**Исем –** предметны, төшенчәне атаучы , аның исемен әйтеп бирүче сүз төркеме.

**Предмет –** чынбарлыктагы әйбер, күренеш.

**Сәнгать, хезмәт, Ватан , табигать, әдәп, әһәмият, таләп һ.б.-** предметлаштырылып бирелгән төшенчәләр.

**Исем -** **кем? нәрсә?** сорауларына җавап бирә

**Исемнәр ике төркемгә бүленәләр**

Бер төрдән булган предметларны берсен башкаларыннан аеру өчен бирелгән исем **ялгызлык исем** дип атала.

Бер төрдән булган предметларның барысы өчен дә уртак исем **уртаклык исем** дип атала.

# Исемнең берлек һәм күплектә килүе.

Шаулап тора яшел урманнар,
Җәелгәннәр тезмә тын таулар,
Кошлар йөзә зәңгәр күлләрдә,
Тирбәләләр гөлләр җилләрдә...
Нефть табыла шушы җирләрдә. ( Нури Арсланов.)

| Берлек санда исем бер предметны белдерә | Күплектә исем күп предметны белдерә |
|---|---|
| бала | балалар |
| юл | юллар |
| кеше | кешеләр |
| төзүче | төзүчеләр |
| урман | урманнар |
| тиен | тиеннәр |
| җиң | җиңнәр |
| миң | миңнәр |

# Татар телендә килешләр

## Татар телендә 6 килеш бар.

| Килешләр | Сораулар | Кушымчалар | |
|---|---|---|---|
| | | калын | нечкә |
| Баш килеш | кем? нәрсә? | --- | ---- |
| Иялек килеш | кемнең? нәрсәнең? | - ның | - нең |
| Юнәлеш килеше | кемгә? нәрсәгә? | - га, - ка | - гә, - кә |
| Төшем килеше | кемне? нәрсәне? | - ны | - не |
| Чыгыш килеше | кемнән? нәрсәдән? кайдан? | -нан, - дан, - тан | - нән, - дән, - тән |
| Урын – вакыт килеше | кемдә? нәрсәдә? кайда? | - да, - та | - дә, - тә |

# Исемнең килеш белән төрләнеше

## Берлек сан

| Килешләр | Сузык авазга беткән исемнәр | | Тартык авазга беткән исемнәр | |
|---|---|---|---|---|
| | калын | нечкә | калын | нечкә |
| Баш килеш | дөнья | кеше | герб | шәм |
| Иялек килеше | дөнья-ның | кеше-нең | герб-ның | шәм-нең |
| Юнәлеш килеше | дөнья-га | кеше-гә | герб-ка | шәм-гә |
| Төшем килеше | дөнья-ны | кеше-не | герб-ны | шәм-не |
| Чыгыш килеше | дөнья-дан | кеше-дән | герб-тан | шәм-нән |
| Урын –вакыт килеше | дөнья-да | кеше- дә | герб-та | шәм-дә |

# Исемнең килеш белән төрләнеше

## Күплек сан

| Килешләр | Сузык авазга беткән исемнәр | | Тартык авазга беткән исемнәр | |
|---|---|---|---|---|
| | калын | нечкә | калын | нечкә |
| Баш килеш | апа-лар | әби-ләр | урам-нар | җиң-нәр |
| Иялек килеше | апа-лар-ның | әби-ләр-нең | урам-нар-ның | җиң-нәр-нең |
| Юнәлеш килеше | апа-лар-га | әби-ләр-гә | урам-нар-га | җиң-нәр-гә |
| Төшем килеше | апа-лар-ны | әби-ләр-не | урам-нар-ны | җиң-нәр-не |
| Чыгыш килеше | апа-лар-дан | әби-ләр-дән | урам-нар-дан | җиң-нәр-дән |
| Урын –вакыт килеше | апа-лар-да | әби-ләр-дә | урам-нар-да | җиң-нәр-дә |

# Фигыль

**Фигыль -** предметның эш- гамәлен, хәл – торышын белдерүче сүз төркеме.

Фигыль **нишли? нишләде? нишләгән? нишләр? нишләячәк?** сорауларына җавап бирә.

нишли? - килә, нишләде? - килде, нишләгән? – килгән
нишләр? – килер, нишләячәк? – киләчәк.

Фигыль ике төркемчәгә бүленә:

**1. хикәя фигыль -** эшнең үтәлү-үтәлмәвен хәбәр итә.

**2.боерык фигыль-** эшкә кушуны , эштән тыюны, боеру, өндәүне, үтенүне белдерә.

# Боерык фигыльнең зат-сан формалары

Барлык формасы Юклык формасы

| Затлар | Сан | Фигыльләр | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | калын төрләнеш | нечкә төрләнеш | калын төрләнеш | нечкә төрләнеш |
| 1 зат | Берлекә | ----- | ------ | ----- | ------ |
| 2 зат | | макта | кис | макта-ма | кис-мә |
| 3 зат | | макта-сын | кис-сен | макта-ма-сын | кис-мә-сен |
| 1зат | Күплекә | ------ | ----- | ------ | ------ |
| 2 зат | | макта-гыз | кис-егез | макта-ма-гыз | кис-мә-гез |
| 3 зат | | макта-сын-нар | кис-сен-нәр | макта-ма-сын-нар | кис-мә-сен-нәр |

# Хикәя фигыльнең заман формалары

| Үткән заман хикәя фигыль | Хәзерге заман хикәя фигыль | Киләчәк заман хикәя фигыль |
|---|---|---|
| -ды/-де, - ты/ - те<br>- ган/ -гән, - кан/ - кән | - а/ - ә, - ый/ - и | -ар/-әр, -ыр/ -ер, -р<br>-ачак/-әчәк, -ячак/ -ячәк |
| оч-ты, өлгер-де<br>оч-кан, өлгер-гән<br>укы-ды, эшлә-де<br>укы-ган, эшлә-гән | оч-а, өлгер-ә<br>ук-ый, эшл-и | оч-ар, өлгер-ер<br>оч-ачак, өлгер- әчәк<br>укы-р, эшлә- р<br>укы- ячак, эшлә-ячәк |

Урманда тәмле җиләкләр өлгерде. / өлгергән.

Урманда тәмле җиләкләр өлгерә.

Урманда тәмле җиләкләр өлгерер. / өлгерәчәк.

# Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат – сан белән төрләнеше.

## Берлек сан

эш – хәлне сөйләүче үзе башкара

**1 нче зат**

бара-м
эшли-м

эш – хәлне сөйләмдә катнашучы кеше башкара

**2 нче зат**

бара-сың
эшли-сең

эш-хәлне сөйләмдә катнашмаучы кеше яки предмет баш-кара

**3 нче зат**

бара
эшли

## Күплек сан

**1 нче зат**

бара-быз
эшли- без

**2 нче зат**

бара-сыз
эшли – сез

**3 нче зат**

бара - лар
эшли - ләр

# Үткән заман хикәя фигыльнең зат – сан белән төрләнеше.

## Берлек сан

**1 нче зат**

хыялланды-м
хыялланган – мын
ишетте – м
ишеткән – мен

**2 нче зат**

хыялланды –ң
хыялланган – сың
ишетте- ң
ишеткән – сең

**3 нче зат**

хыялланды
хыялланган
ишетте
ишеткән

## Күплек сан

**1нче зат**

хыялланды – к
хыялланган-быз
ишетте-к
ишеткән-без

**2 нче зат**

хыялланды –гыз
хыялланган-сыз
ишетте-гез
ишеткән-сез

**3 нче зат**

хыялланды –лар
хыялланган-нар
ишетте-ләр
ишеткән-нәр

# Киләчәк заман хикәя фигыльнең зат – сан белән төрләнеше.

## Берлек сан

| 1 нче зат | 2 нче зат | 3 нче зат |
|---|---|---|
| барыр-мын | барыр-сың | бар-ыр |
| сикерер-мен | сикерер-сең | сикер-ер |
| барачак-мын | барачак-сың | бар-ачак |
| сикерәчәк-мен | сикерәчәк-сең | сикер-әчәк |

## Күплек сан

| 1нче зат | 2 нче зат | 3 нче зат |
|---|---|---|
| барыр-быз | барыр-сыз | барыр-лар |
| сикерер-без | сикерер-сез | сикерер-ләр |
| барачак-быз | барачак-сыз | барачак-лар |
| сикерәчәк-без | сикерәчәк-сез | сикерәчәк-ләр |

# Сыйфат

**Сыйфат** предметның билгесен белдерә.
Сыйфат нинди? кайсы? сорауларына җавап бирә.

**Билге**

| төс | тәм | форма | күләм | масса | холык-фигыль |
|---|---|---|---|---|---|
| яшел | баллы | түгәрәк | озын | җиңел | усал |










Нинди? Кайсы?



# Сыйфат дәрәҗәләре

| Төп дәрәҗә | Чагыштыру дәрәҗәсе | Артыклык дәрәҗәсе | Кимлек дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| Предметның гадәттәге билгесен башка предметның шундый ук билгесе белән чагыштырмыйча белдерә. | Бер предметтагы билгенең башка предметтагы шундый ук билгедән артыграк булуын белдерә. | Бер предметтагы билгенең шундый ук предметтагы билгедән бик артык, иң югары дәрәҗәдә икәнлеген белдерә. | Предмет билгесенең гадәттәгедән ким, азрак булуын белдерә |
| ----- | -рак/-рәк | иң, дөм, кып-, зәп-, ямь-, ап-, сап-, тип-, тап-, һ.б | -гылт/-гелт, -кылт/- келт, су, -сыл/-сел, елҗем,һ.б. |
| кызыл алма | кызылрак алма | кып-кызыл алма | кызгылт алма |

# Зат алмашлыклары

Зат алмашлыклары сөйләмдә исемнәрне алмаштыра.

1 нче зат — мин, без — сөйләүче үзе




2 нче зат — син, сез — тыңлаучы, әңгәмәдәш




3 нче зат — ул, алар — сөйләүдә катнашмаучы



# Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше

| Килешләр | 1 нче зат | | 2нче зат | | 3 нче зат | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | берлек | күплек | берлек | күплек | берлек | күплек |
| Баш килеш | мин | без | син | сез | ул | алар |
| Иялек килеше | минем | безнең | синең | сезнең | аның | аларны ң |
| Юнәлеш килеше | миңа | безгә | сиңа | сезгә | аңа | аларга |
| Төшем килеше | мине | безне | сине | сезне | аны | аларны |
| Чыгыш килеше | миннән | бездән | синнән | сездән | аннан | алардан |
| Урын –вакыт килеше | миндә | бездә | синдә | сездә | анда | аларда |

# Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр

**Бәйлекләр-** җөмләдә сүзләрне бер – берсенә бәйләр өчен хезмәт итә.

Аларның мәгънәсен аңлатып булмый, алар, кушымчалар кебек, үзләреннән алда килгән сүз белән тыгыз бәйләнештә карала:

яшәр **өчен,** нурлары **белән,** тәпиләр **аша**

**Бәйлек сүзләр** дә сүзләрне үзара бәйләү өчен кулланылалар.

**(су) астына, ( су) астыннан, (су) астында –** бәйлек сүзләр

# Кисәкчә

**Кисәкчә сүзгә мәгънә төсмере бирә**

**сөйли ич һичкем язгандыр өйрәндеңме ямь-яшел**

**раслау кире кагу икеләнү сорау көчәйтү**

**мәгънә төсмере**

**Кисәкчә я сүз алдыннан, я сүз артыннан килә.**

1) Аерым: бик ягымлы, дөм сукыр, син генә, торгач ук, өйрәнгән ич, аңладым лабаса, бир инде, барлы да һ.б.

2) Кушылып: һичнәрсә, ашадыңмы, усалдыр, һичкайчан, һичбер, һичничек, йоклачы, күрсәнә, тордыңмыни һ.б.

3) Сызыкча аша: чем-кара, чуп-чуар, яп-якты, өр – яңа, кып-кызыл, һ.б.

# Сүз. Җөмлә

Сүзләр: элә, җимлек, Марат, кош.
Бу сүзләрне тиешле тәртипкә куеп һәм
үзгәртеп,
җөмләләр төзеп була.

1. Марат кошларга җимлек элә.
2. Марат, кошларга җимлек элдеңме?
3. Марат, кошларга җимлек эл!

Җөмлә сүзләрдән төзелә.

Җөмлә тәмамланган уйны белдерә.

Җөмлә хәбәр итә, сорау куя, боера, теләкне белдерә.

Иң кечкенә җөмлә бер сүздән тора: Кыш. Салкын.Ирт

# Җөмлә төрләре

Тыныч тавыш белән әйтелгән җөмлә ахырына нокта (.) куела.

Мөнир урманнан кич кенә кайтты.

Сорауны эченә алган җөмлә ахырына сорау билгесе (?) куела.

-Кая бардың, Мөнир?

Көчле тойгыны, өндәүне бел-дергән җөмлә ахырына өндәү билгесе (!) куела. Андый җөмлә күтәренке тавыш белән әйтелә.

- Их, урман ямьле дә соң, әни!



# Сүзтезмә

Сүзтезмә- предметларның, эш-хәрәкәтенең мәгънәсен
төгәлрәк итеп атый.
Мәсәлән, тау – аерым сүз, гомумән, теләсә нинди тау булырга мөмкин;
биек тау – сүзтезмә, тауны башка таулардан аерып атый.

Сүзтезмә ике яки берничә мөстәкыйль сүздән-
иярүче һәм ияртүче кисәкләрдән тора.
Иярүче сүз ияртүче сүзне ачыклый.
Ияртүче сүздән иярүче сүзгә сорау куела:

нинди?

батыр егет
сыйфат исем

нәрсәне?

Ватанны ярату
исем фигыль

# Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре.

**Ия һәм хәбәр – җөмләнең баш кисәкләре**

**Ия** эшне үтәүчене белдерә, **кем? нәрсә?** сорауларына җавап бирә.

**Хәбәр** ия турында хәбәр итә **нишли? нишләде? нишләгән? нишләр? ул нинди?** һ.б. сорауларга җавап бирә.


**Баш кисәкләрне иярчен кисәкләр ачыклый.**

**Иярчен кисәкләр нинди? ничек? нәрсәне? кайчан? һ.б сорауларга җавап бирә.**

Кайда?

Нинди?

Урамда җылы яңгыр ява.



# Текст

Роман Хикәя Әкият Мәзәк Шигырь Диктант Сочинение Укучының җавабы

**Текст**

**Текст, гадәттә, өч өлештән тора: башлам өлеше**
**төп өлеш**
**ахыры өлеше**

**Эчтәлеге һәм төзелеше ягыннан бербөтен булып оешкан тоташ сөйләм**
**текст дип атала.**

**Текстта һәр җөмлә үзеннән алда килгән җөмләдәге фикерне дәвам итә.**

**Тема – текстның төп эчтәлеге. Ул текстның исемендә күренә.**

**Текстның төп фикере – авторның текстта әйтергә теләгән сүзе.**

# Кулланылган әдәбият:


1. Татар мәктәпләренең башлангыч сыйныф укучылары өчен татар теленнән таблицалар;

2 А.Х. Нуриева, Ч.М.Харисова. Татар теле.1-2 кисәкләр. 2 сыйныф өчен дәреслек, Казан “ Мәгариф” нәшрияты. 2007.

3. А.Х. Нуриева, Ч.М.Харисова. Татар теле.1-2 кисәкләр. 3 сыйныф өчен дәреслек, Казан “ Мәгариф” нәшрияты. 2009.

4. Р.Х.Ягъфәрова, Р.Ә.Асылгәрәева Татар теле.1-2 кисәкләр. 4 сыйныф өчен дәреслек, Казан “ Мәгариф” нәшрияты. 2010